**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 27 ноябрендәге 4889 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Вахитов районы Нариманов урамында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 72 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:011820:11, 16:50:011820:10, 16:50:011820:6;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Вахитов районы, Нариманов урамы;
- билгеләү максаты: электр челтәре хуҗалыгы объекты – җирле әһәмияттәге ТП-57 трансформатор подстанциясе урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, милек хокукы җирле әһәмияттәге ТП-57 трансформаторлы подстанциягә карата теркәлгән (2008 елның 4 сентябре, №16-16-01/258/2008-518).

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

6.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен аларны яраклы хәлгә китерергә;

6.2. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

6.2.1. җир кишәрлекләре «XI – XVIII гасырларда Казан шәһәре тарихи үзәгенең мәдәни катламы», XI – XVIII гасырлар, истәлекле урыны рәвешендә федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашу сәбәпле, Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-п номерлы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә;

6.2.2. 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясен файдалануның характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм хуҗалык эшчәнлегенә таләпләр, Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә проектлау һәм төзү турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән билгеләнгән истәлекле урыннар территориясе чикләрендә хуҗалык эшчәнлегенә карата таләпләрне үтәргә;

6.2.3. җир кишәрлекләре истәлекле урын территориясе чикләрендә урнашкан булуларына бәйле рәвештә алардан файдалану буенча чикләүләрне, атап әйткәндә, җир төзелеше, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм башка эшләрне, мондый эшләр башкару проектларында бу эшләр башланганчы уздырыла торган дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алган истәлекле

урыннарны саклауны тәэмин итү турындагы бүлекләр булмаган очракта, җирнең беренчел өслегеннән 0,3 метрдан тирәнрәк башкаруны тыюны үтәргә;

6.2.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 26 мартындагы 188 номерлы «Татарстан Республикасы төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр исемлеген раслау турында»гы карары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә;


6.2.5. җир кишәрлекләре ЗРЗ(Б)-16 төзелешне һәм хуҗалык эшчәнлеген җайга салу зонасында урнашу сәбәпле, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән «Казан кремле ансамбле», XV гасыр – XX гасырның беренче чиреге (Татарстан Республикасы (Татарстан) федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен раслау, җирләрдән файдалануның махсус режимнары һәм әлеге зоналар территорияләренең чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 27 ноябрендәге
4889 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Вахитов районының Нариманов урамында ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:100
Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдаланунының махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:011820 | кадастр кварталы |
| 16:50:011820:11, 16:50:011820:10, 16:50:011820:6 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |